ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№_172___

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«_29_» _04________2019ел.

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп, б о е р ы к б и р ә м:

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирүнең кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. «Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турында» 2017 елның 10 июлендәге 202 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның «_29_» __04___________ _172____ номерлы боерыгы белән расланды

**Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе**

1. Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына нигезләнеп эшләнде.

Әлеге Тәртип эш бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – Инспекция, граждан хезмәткәрләре) иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте (алга таба – коммерциясез оешма) белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.

Әлеге Тәртип Инспекциядә аларны өчен эшкә алучының вәкиле булып Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы (алга таба – башлык) торган Татарстан Республикасы граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан язмача, шушы Тәртипкә 1 нче кушымтада бирелгән формада төзелә.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупциячел һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны кергән көнендә шушы Тәртипкә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карау эшен гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гаризаны тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуының планлаштырылган функцияләрен билгеләүче язмача аңлатмаларны һәм документларны сорарга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимнәр булырга тиеш.

6. Гариза теркәлгән көннән соңгы биш эш көненнән дә соңга калмыйча Җаваплы зат Гаризаны, Бәяләмәне һәм башка материалларны (булган очракта) теркәп, коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен башлыкка (аның вазыйфаларын башкаручы затка) карау өчен тапшыра.

Башлык (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гаризаны алган көннән соң ике эш көне эчендә карар кабул итә.

7. Җаваплы зат башлык (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан карар кабул ителгән көннән соңгы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа Гаризаның Инспекциянең кадрлар бүлеге мөһере белән таныкланган, башлык резолюциясе куелган күчермәсен кул куйдыртып тапшыра. Башлык резолюциясе куелган Гаризаның төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең әлеге эшенә теркәлә.

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә
1 нче кушымта

________________________________________

________________________________________
(Ф.И.А., биләнә торган вазыйфа,

________________________________________
структур бүлекчә, яшәгән урын адресы,

________________________________________
телефон номеры)

## Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гариза

Миңа (кирәклесенең астына сызарга) түбәндәге белән идарә итүдә катнашырга, аның коллегиаль идарә органы составына керергә рөхсәт бирүне сорыйм

____________________________________________________________________
(иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш,

____________________________________________________________________
гараж кооперативының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең аталышы)

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

___________________________________________сыйфатында түләүсез нигездә

____________________________________________________________________
(бер кеше кулындагы башкарма органның яисә коллегиаль идарә органының аталышы)

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ________________ | ________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибенә

2 нче кушымта

**Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү ЖУРНАЛЫ**

| № п/п | Дата | Үтенеч язуын бирүченең Ф.И.А., вазыйфасы | Үтенечкә кул куйган затның имзасы | Теркәүченең Ф.И.А. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |